СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

21 июнь, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 67 (8079) | Бәясе билгеләнгәнчә

# ЭШТӘ ГЕНӘ ТАБЫП БУЛА ТОРМЫШ ГАМЕН, ТӘМЕН ДӘ...

## «Уңыш - 97» пресс - үзәге хәбәр итә

Район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсеннән алынган мәгълүматлардан күренгәнчә, 20 нче июньгә күпьеллык үләннәрнең 2.920 гектары чабылды. Яңгырлар ешаю сәбәпле соңгы бер көн эчендә район буенча үләннәрнең 340 гектары гына теземнәргә салынды.

1167 тонна печән хәзерләнде. «Кондырча», Киекле, Мичурин исемендәге, Әлмәт, «Таң», «Заря», «Рассвет» күмәк хуҗалыкларында бу эш әйбәт оештырылган.

Район буенча чөгендер плантацияләрен беренче кат эшкәртү төгәлләнеп килә. Аның 4.536 гектары сирәкләнде дә инде. Кукурузның 7.209 гектар мәйданында рәт аралары эшкәртелде.

20 нче июньгә витаминлы үлән оны ясау агрегатларының 14се эшкә җибәрелде. Барлыгы 100 тонна витаминлы үлән оны җитештерелде.

Хуҗалыкларның байтагы дару үләннәре ясауга керешә. Бу көнгә аның запасы 99 тонна тәшкил итә.



Зөфәр Исхакович Волковның соңгы егерме елга якын гомере НГДУ белән бәйле. Идарә оешуның беренче көннәрендә үк килде ул биргә. Баштарак төрле эшләрдә йөрергә туры килде аңа. Соңгы ун артык елын Волков идарәнең төзү-монтаж цехында эшли. Төп вазифасы - торба салу. Зөфәр Исхакович хезмәтен һәрчак җиренә җиткереп башкара. Шуңа да ул цехта иң тәҗрибәле, иң оста торба салучыларның берсе санала.

**Рәсемдә: З.Волков.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## Азык мул булыр

Безнең «Төрнәс» ассоциациясендә терлек азыгы елның - елында мул итеп хәзерләнә. Малларны кыш буена алларыннан калганчы итеп ашатырга мөмкинлек бирә бу.

Азыкны мул итеп хәзерләү өчен мөмкинлекләребез быел да зур безнең. Табигый болынлыкларыбыз байтак, чәчеп үстерелә торган азык культуралары мәйданнарыбыз да зур. Мисал өчен, күпьеллык үләннәр генә дә 450 гектар мәйдан били. Бер генә участокта да үләннәр «карт» түгел, куе һәм биек булып үсәләр. Быел да үләннәр күкрәп үсте. Инде шактый мәйданда алар чабылды да. Кипшенгән үләннәр сыйфатлы килеш кибәннәргә дә өелә. Бүгенге көнгә басуда берничә кибәнебез булды инде. Ә тулаем җәйге сезон дәвамында хуҗалыктагы һәр баш шартлы терлеккә 30 центнер азык берәмлеге күләмендә терлек азыгы хәзерләүне максат иттек.

**А.ТИТОВ,**
**баш агроном.**



## Гомергә, мәңгегә истә калыр

Чыгарылыш класс укучыларына урта мәктәпне тәмамлау турында аттестатлар тапшыру бу атнаның иң истәлекле вакыйгасыдыр, мөгаен. Шәһәрнең 1 нче мәктәбендә ул 19 июнь көнне иртә белән булды. Бирегә, актлар залына укучылар, укытучылар, ата - аналар җыелды. Дулкынландыргыч минутларның атрибутлары - чәчәкләр, елмаюлар, фотого төшүләр... 11 нче сыйныф укучыларына аттестатлар һәм медальләрне мәктәп директоры Фәрит Ислам улы Гайнуллин тапшырды. Мәктәп тарихында беренче буларак быел биш укучы алтын һәм 9 укучы көмеш медальгә лаек булды. Беренче булып алтын медальне Эдуард Алтынбаев, аның артыннан Лилия Әһлиуллина, Рафаэль Язданов һәм ике Люда Гребенкова һәм Гордеева алдылар. Ата - аналар исеменнән чыгыш ясаучы Татьяна Викторовна Соловьева һәм класс җитәкчесе Рәисә Хисмәтулла кызы Садретдинованың чыгышлары балаларны катлаулы олы тормышта үз юлларын табарга, кыенлыклар алдында югалып калмаска өндәде. Кече яшьтәге укучылар директор урынбасары В.А.Орешина җитәкчелегендә алар өчен концерт программасы да әзерләгән иделәр. Ә менә баян тавышы астында мәктәп вальсын барысы да бергә башкардылар - олылар да, балалар да. Киләчәккә ниятләре турында кызыксынгач, Лилия Әһлиуллина (11"А») серен чиште: - Балачактан артист булырга хыялландым. Әмма нефть институтына керәм, экономист булачакмын. Бу реаль. Мәктәпкә килгәндә, уку еллары һәрвакыт минем истә калачак.

Гүзәл Шакирҗанова (11 «В»):

- Биредә колледжда укыдым. КГТУга кердем. Әмма бер елдан соң инженерлыктан экономика факультетына күчәргә уйлыйм.

Елена Никифорова (11 «Б»):

- Бүген мин көмеш медаль алдым. 9 нчы сыйныфта ук юрист булырга карар кылган идем. Бу тормышта дөреслекне табарга юл ярырга кирәк. Иртәгә Бөгелмә индустриаль - педагогия училищесына тапшырам документларны, анда шундый бүлек бар, аннан - институтка.

Әйбәт хыяллар белән таралышалар кичәге 11нчеләр. Тормышта үз юлларын тапсыннар иде алар.

**Т.НАЗАРОВА.**

## Таңнан төнгәчә

«40 лет Победы» КФХАның Сәлим Минһаҗетдинов җитәкчелегендәге кооперативы азык культуралары игү белән шөгыльләнә. Егетләр язын күпьеллык үләннәрне тырмалап, үзләре үк тукландырдылар да. Хәзер исә үләннәрне чаптыру, киптерү белән мәшгульләр. 15 кешедән торган бу кооператив таңнан төнгәчә басуда була. Минһаҗетдинов егетләре бик тырыша. Күпьеллык үлән басуларында әледән- әле «үсеп» чыгучы кибәннәр дә шул хакта сөйли.

**Р.СӘМИГУЛЛИН.**

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

**«Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына икенче яртыеллыкка язылу бәясе дә элеккечә, ягъни 23.400 сум көенә калды. Район газетасына язылып куйсагыз, ел ахырына кадәр районлдагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышанадырабыз.**

***Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!***

## Җәй - мул сөт чоры

# ҮЗГӘРЕШЛӘР - УҢАЙГА

«Төрнәс» КФХАның савым маллары өч лагерьда асрала быел. Терлекләрне тәүлек буе көтү оештырылган: мул үләнле болыннарда, урман аланлыкларында утлап йөриләр алар. Савым өчен лагерьларга кайтарылгач, өстәмә азык та бирелә терлекләргә. Аннары быелгы җәйләү чорында терлекчеләр белән дә проблема тумады: көтүчеләр, азык ташучыларга кытлык юк, савучылар да җитәрлек. Лаборантлар, ясалма орлыкландыручылар да лагерьлардан кайтып кермиләр.

-Хезмәтне никадәр генә дөрес оештырсаң да, кеше факторының нәтиҗәлелеге югары шул,- ди хуҗалыкның баш зоотехнигы Н. И. Шугаев лагерьдагы хәлләр турында сөйләгәндә- әнә, быел кызыксындыру булгач савучыларыбыз югары күтәренкелек белән эшлиләр.

Әйе, хуҗалык администрациясе савучыларның эш хакын хезмәтнең ахыргы нәтиҗәләренә, ягъни санга да, сыйфатка да бәйле ясаган. Шуңа да, кышлату чоры азагында ук «үсеш» алган савым, җәйләүгә күчкәч тагын да арткан һәм ул бүген узган елның шул чорындагыдан 3 килограммга күбрәк. Сыйфат күрсәткечләре дә сөенерлек: быелның биш аенда дәүләткә сатылган сөтнең 96 проценты беренче сорт белән кабул ителгән, 84 проценты сөт-май комбинатына суытып озатылган. Нигездә хисапчы-лаборант Александра Сотникова тырышлыгы нәтиҗәсе дип кабул итәргә кирәк моны.

Савучылар турында да мактау сүзләре генә әйтәсе килә. Әнә Төрнәс бүлекчәсеннән Нурзия Галимова, үзәк бүлекчәдән Татьяна Мизонованың биш айда һәр сыердан савылган сөтләре ике мең килограммга аз гына җитми. Валентина Никифорова да хезмәттәшләре кебек үк быел уртача савымны 4 мең килограммга җиткерергә ниятли. Савучыларның башкалары да сөтне күп савалар. Югыйсә әле байтагының сыерлары да бозаулап бетмәгән. 120 ләп сыер икенче яртыеллык башында бозаулаячак. Әмма хуҗалыкта 324 баш бозау алынган. Баш зоотехник моны орлыкландыручылар Флюра Галимова һәм Валентина Степанованың профессиональлегенә, тырышлыгына бәйли.

-«Бушка» эшләмәделәр, орлыкландырылган һәр сыер бозаулады,- ди Николай Иванович.

Бозаулар дигәннән, хуҗалыкта быелгы елдан аларны юнәлешле үстерү буенча нәтиҗәле эш башланыр төсле. Әле менә 140 баш тана Александр Брусов һәм Рәшит Гыйльметдинов карамагына тапшырылган. Яхшы нәселле сыерлардан туган маллар алар. Бүгенге көндә 460-480 килограммга җиткән малларның байтагы каплатылган да инде. Димәк, ел азагында савым көтүе яшь, өметле маллар исәбенә тулыланачак. Бу эшкә игътибар кимеми. Хәзер, мәсәлән, үзәк бүлекчәдә бер абзар малларны салкында асрау өчен реконструкцияләнә. Төрнәс бүлекчәсендәге реконструкциянең максаты исә быелгы кыштан аерым бер группа малларны бәйсез асрауны күздә тота.

Гомумән, соңгы вакытта «Төрнәс»тә сөт терлекчелегендә уңай якка үзгәрешләр байтак. Дәвамлы гына була күрсеннәр инде алар.

**Р.ГИНЯЕВА.**



## 22 июнь - Ватанны саклаучыларны искә алу көне

### *Алар исемен урамнарыбыз йөртә*



# Н.Ф.Ватутин урамы

Украина башкаласы Киевта, киң Днепр өстендә армия генералы Н.Ф.Ватутинга мәһабәт һәйкәл тора. Полководец поход шинеле кигән. Рядовой кызылармеецтан армия генералы, фронт командующие- Н.Ф. Ватутинның сугышчан юлы шундый.

Николай Федорович 1901 елның декабрендә элеккеге Воронеж губернасының Чепухино авылында күп балалы крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч мәктәпне уңышлы тәмамлаганнан соң, аны, укытучы киңәше буенча, коммерция училищесына билгелиләр. 4 ел бик тиз үтеп китә, зур булмаган стипендия түләүне дә туктаталар. Николай туган авылына кайтырга мәҗбүр була.

Кызыл Армиягә кергәндә, аңа әле 18 дә булмый. Махночыларга каршы сугыша, үзен кыю сугышчы итеп күрсәтә.

Полтава пехота мәктәбе, взвод, рота командиры, начальник ярдәмчесе, аннан соң тау укчы дивизиясенең штаб начальнигы. Ул Киевта югары хәрби мәктәпне, М.В.Фрунзе исемендәге хәрби академияне, Генераль штаб академиясен тәмамлый. 1938 елда - Киев аерым хәрби округы начальнигы, 1940 елда - РККА Генераль штаб начальнигының беренче урынбасары.

Кырыс сугыш елларында генерал Ватутинның полководец таланты тулысынча ачыла. Төньяк - Көнбатыш фронт начальнигы, Воронеж, Көньяк - Көнбатыш, беренче Украина фронтлары командующие. Брянск, Сталинград, Курск көрәшләре, Украинаны азат итү.

Днепр һәм Киев өчен көрәштә Ватутинның таланты аеруча ачык чагыла. Аның җитәкчелегендә сугышчылар 1943 елның 6 ноябрендә Украина башкаласы Киевны азат иттеләр.

Һөҗүм дәвам итә. Сугышчылар көнбатышка баралар. Ватутин фронтның төрле участокларына чыга, армия, дивизиядә, хәрби хәрәкәтләрдә була.

1944 елның февралендә, 30 нчы армия штабыннан кайтканда Ватутин 4 машина һәм 10 кешедән торган шәхси сагы белән Милятино авылына кергәндә бандит бандерачылар һөҗүменә юлыгалар. Атыш китә, машиналар яндырыла. Әйләнеш оборонасын алып, сугышчылар ут ачалар. Рядовой Хәбибуллин пулеметтан ата башлый.

Н.Ф.Ватутин атыш вакытыныда авыр яралана. Аны ашыгыч рәвештә Киевка эвакуацияләләр. Мәскәүдән килгән тәҗрибәле табиблар генерал гомерен саклап калу өчен көрәшәләр, әмма саклап кала алмыйлар. 1944 елның 15 апрелендә армия генералы Николай Федорович Ватутин һәлак була. Аңа бары 42 яшь була.

Н.Ватутин - Советлар Союзы Герое, Ленин, Кызыл Байрак, I дәрәҗә Суворов һәм Кутузов орденнары һәм башка хәрби бүләкләргә лаек була.

Шәһәребезнең бер урамы аның исемен йөртә.

**Рубриканы**
**И.САНДЛЕР**
**алып бара.**

**Рәсемдә: Сталинград астында. Сулдан уңга Көньяк - Көнбатыш фронты гаскәрләре командующие, армия генералы Н.Ф.Ватутин, фронтның хәрби совет члены, генерал - майор А.С.Желтов, һава армиясе командующие, авиация генерал майоры С.А.Красовский.**

# Чәйнәп биргәнне йота белмәсәң...

Салымнар турында язгалап торабыз, тик сүз нигездә түләнмәгән салымнар турында була. Анысы аңлашыла да, чөнки законда каралган салым суммасын түләми хәлең юк. Әмма салым белән салым арасында аерма булган кебек, кайбер салымнарны түләү срогы кичектерелүе дә, азрак кына башыңны эшләтсәң, кайбер түләүләрне бөтенләй башка юнәлешкә борырга мөмкинлеге дә булуын истән чыгармаска кирәк. Болай дигәндә иң элек фәнни - тикшеренү һәм тәҗрибә - конструкторлык эшләренең республика фондына (НИОКР) салым түләүләр турында әйтүебез.

НИОКР фондына акча күчерү районндагы 56 предприятие һәм оешма өчен түләү мәҗбүри булган салымнарның берсе булып тора. Салымның суммасы реализацияләнгән (урнаштырылган) продукция, хезмәт төрләренең гомуми үзкыйммәтенең 1,5 проценты кадәр итеп билгеләнә. Районда андый салымның иң зур суммасы шикәр заводында, сөт - май һәм ит комбинатларында, җылылык челтәрендә, хуҗалыкара төзелеш оешмасында һәм элеваторда,урман хуҗалыгында, азык - төлек комбинатында... Калганнарында ул салымның суммасы да әллә ни зур түгел кебек, әмма район буенча быелның беренче кварталы өчен генә дә НИОКР фондына күчереләсе акчаның гомуми суммасы 1 миллиард 160 миллион сумга җыела.

Гомуми сүзенә басым ясавыбыз очраклы түгел, чөнки положение нигезендә НИОКР салымы суммасының яртысы шунда ук фондның үзәкләштерелгән өлешенә күчерелә, ә икенче яртысы производствоны үстерүгә юнәлтелгән фәнни - тикшеренү, тәҗрибә - конструкторлык эшләренә тоту өчен бер календарь ел буена предприятие яки оешма карамагында калдырыла. Һәм мәсьәләгә хуҗаларча караганда ул сумманы тулысы белән предприятиенең үзендә калдырырга мөмкин. Ник дисәң, ул средстволар предприятиедә:- фәнни - тикшеренү, тәҗрибә - конструкторлык һәм тәҗрибә - технологик эшләрне;

- конкуренциягә сәләтле һәм чит илдән кертелә торганны алыштырырдай продукцияләр чыгаруны;
- продукциянең тәҗрибә - промышленность үрнәкләрен әзерләүне;
- яңа төр продукцияләр эшләү һәм үзләштерүне;
- рационализаторлык һәм уйлап табучылыкны яклау чараларын финанслауга тотылырга мөмкин һәм тиеш. Ә кайсы гына предприятиедә дә, бигрәк тә хәзерге шартларда бу эшләрнең барысы да булмаса да, берничә юнәлеше күпмедер дәрәҗәдә барыбер алып барыла бит. Шул эшләрне тиешенчә кәгазьгә төшерү һәм рәсмиләштерү генә мөһим. Моның өчен шушы юнәлештә күздә тотылган эшләрнең гыйнварның 15енә кадәр планын төзергә, предприятие җитәкчесе приказ белән ул планны расларга һәм аны үтәтү өчен җаваплы кеше билгеләргә тиеш. Күздә тотылган барлык эшләргә дә ел тәмамлангач, икенче елның 15 гыйнварена кадәр отчет ясала. План да, отчет та НИОКР фонды белән килештерелә, монысы югарыда телгә алынган эшләргә фонд тарафыннан акча бүленү, икенче төрле әйтсәк, НИОКР салымының предприятие карамагында калдырылып торылган фондын файдаланырга рөхсәт алу өчен кирәк. Ул юнәлештәге эшләр аеруча әһәмиятле һәм масштаблы булган очракта НИОКР фонды җитмәгән сумманы фондның үзәкләштерелгән өлешеннән дә финанслар предприятиенең үзендә терсәкле валларны сафка бастыруны җайга салу буенча башкарылган эшләр шулай ук тиешенчә рәсмиләштерелгән һәм НИОКР фонды белән килештерелеп 39 миллион сум акча тиешле максатка тотылган, ягъни,эш тә эшләнгән,салым да түләргә туры килмәгән.

Кызганычка каршы, мондый мисаллар район буенча санаулы гына әле. Аерым алганда, җылылык челтәрендә, шикәр заводында производствоны фәнни -техник үстерү, яңарту һәм камилләштерү планнары төзелгән һәм килештерү өчен НИОКР фондына тапшырылган. Ул планнар фондта раслангән очракта предприятиеләрнең шактый акчалары янга калырга, дөресрәге әрәмгә китмәскә мөмкин. Югыйсә бит бик кызык парадокс килеп чыга: предприятиедә яңа техника һәм технология кертү кебек һәм шуңа охшаш зур гыларга мөмкин.

Районда бу юнәлештә нәтиҗәле генә эшләүче берничә предприятие бар. Мәсәлән, сөт - май комбинатында эремчекне төргәкләп чыгару линиясен сафка кертү буенча планлаштырылган һәм гамәлгә ашырылган эшләрен тиешенчә рәсмиләштерү нәтиҗәсендә 1995 ел өчен 70 миллион сум, былтыр 120 миллион сум салым суммасын предприятиенең үзендә калдырдылар. Бирдә 1997 елга планлаштырылган чаралар да тиешенчә рәсмиләштерелгән һәм ул план НИОКР фондына җиткерелгән.«Сельхозтехника» район берләшмәсендә дә булына, күп чыгымнар сорый һәм шактый икътисадый эффект бирә торган эшләр башкарыла. Әмма шуларны тиешенчә рәсмиләштермәү аркасында, нәкъ шундый характердагы эшләрне башкарган өчен салым түләргә туры килә. Эшен дә эшлә, шуны эшләмәгән өчен дип салым да түлә булып чыга бит инде бу.Район буенча 1994 елда бу төр салымның предприятиеләрнең үз карамакларында калырга мөмкин булган суммасы 698 миллион сум булып, аның бер генә тиене дә үзләштерелмәгән, 1995 елда шундый төр сумманың 5,7 проценты, былтыр 28,2 проценты үзләштерелгән. Өч елда мөмкин булган 4 миллиард 900 миллион сумнан күбрәк сумманың 18 проценты гына тотылган, ә калган сумма салым буларак түләнергә тиешле исемлеккә кертелгән. Әле ярый да бит предприятиенең счетында акчасы булып ул түләүне вакытында башкарырга мөмкин булса, ә мөмкинлеге булмаса, түләнмәгән суммага һәр көн саен 0,3 процент пеня салына бит әле.


Предприятеләрдә баш бухгалтерлар НИОКР салымының суммасын бик ачык белеп торалар, производство өчен турыдан -туры җаваплы баш инженерлар да производствоны камилләштерү һәм башка шул юнәлештәге эшләр өчен үзләре һәм алар кул астындагы службалар, беренче чиратта производство - техник бүлекләр җаваплы икәнлеген ачык аңлыйлар. Тик, кызганычка каршы, башкара торган (күп кенә очракларда башкарган да) эшләрен тиешенчә рәсмиләштермәү аркасында күпме акчаны җилгә очыруга юл куялар. Ә бит район буенча ул сумма шактыйга ук җыела.

Күренгәнчә, уйлабрак эш итмәү, берничә кәгазь язарга иренү аркасында никадәр акчаны файдаланырга мөмкин булып та, салым рәвешендә чыгарып салырга туры килә. Чәйнәп биргәнне йота белмәү кебегрәк була түгелме соң инде бу?

**Р.МИННЕГАЛИЕВ,**
**салым инспекциясе начальнигы.**
**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

**Мидхәт Миншин**

## *Капкаларда йолдызлар*



***Барам урам уртасыннан-***
***Күзләрем капкаларда.***
***Һәр өйнең сугышка киткән***
***Кемедер кайтмаган ла.***

***Кемнең - улы, кемнең -ире,***
***Кемнең- яры, җанашы.***
***Исемнәре капкаларда-***
***Йөрәкләрдә ярасы.***

***Һәр өй юксына улларын,***
***Һәр нигез сызланадыр.***
***Батырларның рухы кайтып,***
***Кабыза йолдызларын.***

***Кайтмый калганнар сафыдай***
***Йолдызлар капкаларда.***
***Билгесез түгел батырлар,***
***Кайларда ятсалар да.***

# TV

### ПОНЕДЕЛЬНИК, 23 июня
**«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
18.10 Мультфильм
18.15 "Бизнес - коктейль"
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Замандаш циклыннан". "Без татарлар"
19.30 Зәһрә Шәрифуллина җырлый
19.45,21.45 Новости
20.00 "Видеогид"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Сәхнә утлары"
22.00 "Клуб Болл"
22.25 "Карт - бланш"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 1.00 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 Поле чудес.
11.00 Футбольное обозрение.
11.30 19.35 "Угадай мелодию".
12.15 КВН-97
14.30 Человек и закон.
15.20 "Сказки тихого часа"
15.45 Марафон-15
16.05 Звездный час
16.40 "Гарри - снежный человек"
17.05 ...До шестнадцати и старше
17.30 "Вокруг света"
19.10 Час пик
20.00 Мы
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время
21.45 "Полтергейст-2"
22.40 "Другие берега"
23.20 "Фучжоу"
1.10 Пресс-экспресс

**РОССИЯ**

7.00, 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 "Вести"
7.15, 8.15 "С добрым утром"
9.00 Православный календарь
9.05, 16.25 "Клубничка"
9.35 "Сам себе режиссер.
10.10, 19.00 "Санта-Барбара"
11.15 "Парламентский вестник"
11.45 "Графоман"
12.00 "Третья Мещанская"
13.40 "Ретро-шлягер"
13.55 "Магазин недвижимости"
14.25 Тихий дом.
15.05 "Иванов, Петров, Сидоров и другие"
15.45 Шестое чувство.
16.10 Соотечественники.
17.15 "Там-там новости"
17.25 "Лукоморье"
17.50 "Посмотри на себя"
18.05 "Россияне"
18.20 "Пульс"
20.35 "Добрый вечер"
21.25 "Шутка", тайна земли".
22.45 "Дежурная часть"
23.30 "Щелкунчик"
23.40 "Убийство императора.Версии"
0.55 "На ночь глядя"
1.10 "Товары-почтой"

### ВТОРНИК, 24 ИЮНЯ
**«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан".
18.40 Мультфильм
18.45, 20.45 "Җиһан"
19.00 "Галәм галәмәтләре"
19.20 "Татар халык моңнары"
19.45,21.45 Новости
20.00 "Карт - бланш"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Зимний вечер в Ганрах"
22.35 "Виртуаль тәэсирләр"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 23.50 Новости
9.15, 18.20 "Девушка по имени Судьба"
10.05 "Мы"
10.45 Смехопанорама
11.25 Домашняя библиотека
11.30, 19.35 Угадай мелодию
12.15 "Два капитана".
13.35 "Что? Где? Когда?"
15.20 "Сказки тихого часа"
15.45 Кварьете "Веселая Квампания"
15.55 Мультитроллия
16.15 Волшебный мир, или Синема
16.40 "Гарри - Снежный человек"
17.05 ...До шестнадцати и старше
17.30 "Вокруг света"
19.15 Час пик
20.05 Тема
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время
21.45 "Мачеха"
23.20 "Жизнь замечательных людей"
0.00 Пресс-экспресс

**РОССИЯ**

7.00, 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 "Вести"
7.15, 8.15 "С добрым утром"
9.00 Православный календарь
9.05, 16.25 "Клубничка"
9.35 Караоке по-русски.
10.00, 19.00 "Санта-Барбара"
11.15 "Пульс"
11.40,11.55 "Графоман"
13.55 Магазин недвижимости.
14.25 "Кто мы? "
15.05 "Иванов, Петров, Сидоров и другие"
15.45 Образ жизни.
16.10 Соотечественники.
17.15 "Там-там новости"
17.25 "Лукоморье"
17.50 "Посмотри на себя"
18.05 "Россияне"
18.20 "Новое "Пятое колесо"
20.35 "Добрый вечер"
21.20 "Манька","Крейзи"
22.25 "Момент истины"
23.45 "Убийство императора.Версии"
1.00 Горячая десятка.
1.55 "На ночь глядя"
2.10 "Товары-почтой"

### СРЕДА, 25 ИЮНЯ
**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
18.25 Мультфильм
18.35 "Служба 01"
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 "Авыл"
19.30 "Өч бард аккорды..."
19.45,21.45 Новости
20.00 "Энергосбыт - тепла и свет поток несущий..."
20.15 "Пульс"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Раба любви"
22.30 "Вопросы из записной книжки"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 23.55 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 Тема.
10.40 В мире животных
11.25 Домашняя библиотека.
11.30 19.35 "Угадай мелодию".
12.15 "Два капитана".
13.25 "В лесной чаще".
13.45 "Колесо истории"
14.25 Служу России!
15.20 "Сказки тихого часа".
15.45 Кактус и К.
15.55 До-ми-соль.
16.15 Зов джунглей.
16.40 "Гарри-снежный человек".
17.05 "До шестнадцати и старше"
17.30 "Вокруг света"
19.05 Футбол.Чемпионат России.
21.00 Время.
21.45 "Вас ожидает гражданка Никанорова"Х.ф
23.15 "Тэфи-97"
0.05 Баскетбол.
0.55 Пресс - экспресс.

**"РОССИЯ"**

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.00 Православный календарь.
9.05 16.25 "Клубничка".
9.35 L-клуб.
10.10 19.00 "Санта - Барбара"
11.15 Новое пятое колесо.
11.45 Графоман.
12.00 "Женщина со средствами". Х/ф
13.28 Киноанонс.
13.30 Мультфильм.
13.40 "Ретро-шлягер"
13.55 "Магазин недвижимости".
14.25 "В доме на две улицы..."
14.50 Ноу хау.
15.05 "Иванов, Петров, Сидоров и другие".
15.45 Парламентарий.
16.10 Соотечественники.
17.15 Там-там новости.
17.25 Лукоморье.
17.50 "Посмотри на себя"
18.05 "Россияне"
18.20 "Люди,деньги, жизнь".
20.35 Добрый вечер.
21.20 "Нижегородская ярмарка -97"
23.40 "Убийство императора.Версии"
0.55 Кафе Обломов.
1.35 "На ночь глядя".
1.50 "Товары - почтой".



### ЧЕТВЕРГ, 26 ИЮНЯ
**«ТАТАРСТАН»**

7.00-8.00 "Чулпан"
18.40 Мультфильм
18.45,20.45 "Җиһан"
19.00 Татарстанның дәүләт телерадиокомпаниясе оркестры уйный
19.20 "Артист. Годы. Творчество." Әхмәт Кәлимуллин
19.45,21.45 Новости
20.00 "ГАИ - информ"
20.10 "Точка опоры"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Родня"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.10 Новости.
9.15 18.20 "Девушка по имени Судьба".
10.00 Клуб путешественников
10.55 Домашняя библиотека.
11.00 Смак.
11.20 "Чтобы помнили..."
12.15 "Повесть о первой любви "Х.ф
13.45 Баскетбол.Чемпионат Европы.
15.20 "Сказки тихого часа"
15.45 Остров Чунга-Чанга.
16.15 Лего-го!
16.40 "Гарри-снежный человек".
17.05 ...До 16 и старше.
17.30 Вокруг света.
19.10 Час пик.
19.35 "Джентельмен - шоу".
20.05 "Моя семья".
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.45 " С меня хватит "Х.ф
23.40 " Магия: мир сверхъестественного "
0.15 Баскетбол.Чемпионат Европы.
1.10 "Пресс-экспрес".

**"РОССИЯ"**

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.05 16.25 "Клубничка".
9.35 Бесконечное путешествие.
10.10 19.00 "Санта-Барбара".
11.15 "Люди,деньги,жизнь".
11.45 Графоман.
12.00 " Женщина со средствами"Х.ф.
13.35 1.00 "Нижегородская ярмарка -97"
13.45 Ретро-шлягер.
13.55 "Магазин недвижимости".
14.25 Момент истины.
14.50 Репортаж ни о чем.
15.05 "Иванов, Петров, Сидоров и другие".
15.45 На пороге века.
16.10 Соотечественники.
17.15 Там-там новости.
17.25 На острове ТЮЗ.
17.50 Посмотри на себя.
18.05 Россияне.
18.20 "Избранные"
20.35 Добрый вечер.
21.25 В XXI век - без наркотиков.
23.45 "Убийство императора. Версии".
1.55 "На ночь глядя"
2.10 "Товары - почтой".

### ПЯТНИЦА, 27 ИЮНЯ
**«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
18.05 "Отцы". 1-я серия
18.45.20.45 "Җиһан"
19.25 "Дин һәм тормыш"
19.45,21.45 Новости
20.00 "В Госсовета Татарстана"
20.30 "Әлли - бәлли - бәү"
21.00 "Җомга көн кич белән"
22.00 "Видеоспорт"
22.25 "Замандаш" циклыннан. "Шундый кеше инде ул Галиев"

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро"
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.10 Новости
9.15, 18.20 "Девушка по имени Судьба"
10.00 Моя семья
10.40 Пока все дома
11.20 Домашняя библиотека
11.30 Играй, гармонь, любимая!
12.15 "Дама с попугаем"
13.50 Баскетбол. Чемпионат Европы.
15.20 "Сказки тихого часа"
15.45 "Принц- привидение"
17.05 ...До 16 и старше
17.30 "Вокруг света"
19.20 Человек и закон
19.50 Поле чудес
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время
21.45 "Лебединая песня"Х.ф
23.25 Взгляд
0.20 Баскетбол. Чемпионат Европы.
1.10 Пресс-экспресс
1.25 "Возвращение охотника"Х.ф.

**"РОССИЯ"**

7.00, 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 "Вести"
7.15, 8.15 "С добрым утром"
9.00 Православный календарь
9.05, 16.25 "Клубничка"
9.35 "Аншлаг" представляет...
10.10, 19.00 "Санта-Барбара"
11.15 "Избранные"
11.45 "Графоман"
12.00 "Женщина со средствами" Х.ф
13.35 "Нижегородская ярмарка -97"
13.45 "Ретро-шлягер"
13.55 "Магазин недвижимости"
14.25 Булгары. У истоков веры.
14.50 "Красная книга"
15.05 "Иванов, Петров, Сидоров и другие"
15.45 "Золотая карта России"
16.10 "Ничего, кроме..."
17.15 "Там-там новости"
17.25 "Лукоморье"
17.45 "Посмотри на себя"
18.05 "Россияне"
18.20 "Парламентский вестник"
20.35 "Добрый вечер"
21.10 " Подиум д^арт"
23.30 Программа передач.
23.35 "Огарева, 6"
1.07 "Ночной экспресс"
1.50 "На ночь глядя"
2.05 "Товары - почтой"

### СУББОТА, 28 ИЮНЯ
**«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
17.40 Мультфильм
17.45 Г.Ахунов. "Габбас хәзрәт"
18.45 "Җиһан"
19.00 "Бизнес - коктейль"
19.35 "Из личной жизни"... дома"
19.45 Новости
20.00 "Досье 02"
20.15 "Әлли - бәлли - бәү"
20.30 "Әй, моң дәрьясы, бер тамчың булсам иде"

**ОРТ**

8.00 "Зеленый огонек"
9.10 Мультфильмы нашего детства.
9.40 Лотто "Миллион"
9.45 Домашняя библиотека
10.00, 15.00, 18.00 Новости
10.10 Слово пастыря
10.30 Утренняя почта
11.05 "Каламбур"
11.40 Смак
12.00 Возвращение Третьяковки
12.25 "Не могу сказать "прощай"
13.55 Баскетбол.
14.25 Если у Вас требуют взятку. "Если..."
15.20 Очевидное-невероятное
15.50 "Союзмультфильм" представляет...
16.40 В мире животных.
17.15 "Колесо истории"
18.20 КВН-ассорти.
19.00 "Воры в законе"Х.ф.
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время
21.55 "Когда мы встретимся вновь"
22.45 "Что? Где? Когда?"
0.05 "Элвис"

**РОССИЯ**

8.00 "Утренний экспресс"
8.55 "Товары - почтой"
9.05 "Меморина"
9.30 "Клуб "Адреналин"
9.45 "Доброе утро, страна!"
10.30 "Пилигрим"
11.00 "Вести в одиннадцать"
11.15 "Как много девушек хороших..."
11.55 "Москва златоглавая".
12.50 В мире животных.
13.15 "Нижегородская ярмарка-97"
13.25 "Анонимные собеседники"
14.00 "Вести про..."
14.20 "Расстанемся, пока хорошие "Х.ф
15.40 Дорогая моя столица.
15.55 Сад культуры.
16.20 Караоке по-русски.
16.50 Двойной портрет.
17.15 "Бесконечное путешествие"
17.45 Иосиф Кобзон. Прощальный тур.
18.00 "Эхо под куполом цирка"
18.55 Аншлаг и Ко.
20.00 Вести.
20.35 "Сам себе режиссер"
21.15 Совершенно секретно.
22.10 Программа передач.
22.15 "Нижегородская ярмарка-97"
23.15 Репортер.
23.30 " В поисках души"

### ВОСКРЕСЕНЬЕ, 29 ИЮНЯ
**«ТАТАРСТАН»**

7.00 - 8.00 "Чулпан"
18.30 "Хәерле сәгатьтә"
19.30 "ТОН"
20.15 "Автокалейдоскоп"
20.30 "Телебуклет"
20.40 "Әлли - бәлли - бәү"
20.50 "Шаян шоу"
21.35 Лирик концерт
22.10 "Сирены"

**ОРТ**

8.00 "Овод"Х.ф
9.40 Мультфильмы нашего детства .
9.55 "Спортлото".
10.00 15.00 Новости.
10.15 Непутевые заметки.
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 Армейский магазин.
12.30 "Играй, гармонь любимая"
13.00 "Сельский час"
13.25 "Подводная одиссея команды Кусто"
14.25 Смехопанорама.
15.15 "Приглашение к музыке"
15.45 Клуб путешественников.
16.30 Мультфейерверк.
17.25 Футбольное обозрение.
17.55 "Один на один".
18.25 "Счастливый случай"
19.20 "Налево от лифта"
20.50 Киноафиша..
21.00 Время.
21.40 "Когда мы встретимся вновь"
22.30 "Клуб "Белый попугай"
23.20 Баскетбол.Чемпионат.Европы.

**"РОССИЯ"**

8.00 Утренний экспресс.
8.55 "Торговый дом "Ле Монти".
9.10 "Солти". Телесериал.
9.35 "У всех на устах".
9.50 Доброе утро, страна!
10.30 Присяга.
11.00 14.00 Вести.
11.15 Русское лото.
11.55 "Без пяти двенадцать".
12.00 "Книжная лавка".
12.25 "Человек на земле".
12.50 Поют драматические артисты.
13.15 Репортаж ни о чем.
13.30 21-й кабинет.
14.20 "Расстанемся, пока хорошие"Х.ф.
15.30 Волшебный мир Диснея.
16.30 "Довгань-шоу".
17.00 Весь мир.
17.40 "Горячая тема"
18.05 " Один против всех".
18.25 L-клуб.
18.55 "Ситуация"
19.10 "Аншлаг" представляет.
19.45 "РТР в гостях у телезрителей".
20.35 "Колизей"
21.30 Футбол без границ.
22.00 Городок.
22.35 "Нижегородская ярмарка -97"
23.55 У Ксюши.
0.55 Частная коллекция.
1.20 Рек-тайм.
1.40 "Гороскоп и видеомедитация"

*Базар*

# ХЕЗМӘТНЕ ДӨРЕС ОЕШТЫРСАҢ...

Бүгенге көндә табышлы эшләп, ни эшчеләргә хезмәт хакы түләүдә, ни клиентларга, партнерларына яисә налог буенча бурычы булмаган предприятие бармы икән? Булса да бик сирәктер. Ә менә «Татпотребсоюз»ның Н-Октябрь ваклап-түмәрләп сату предприятиесеннән үзгәртеп оештырылган «Н - Октябрь төзелеш материаллары» акционерлык җәмгыяте шулай яши бүген.

- Агач сәүдә базасының сәүдә складларыннан башланган һәм еллар үтү белән дә шәһәр һәм район халкын төзелеш материаллары һәм халык кулланыуы товарлары белән тәэмин итү кебек төп функциясен үзгәртмичә эшләүче мөстәкыйль предприятие ул.

Билгеле инде, предприятиенең компактлы булуы аз роль уйнамый бу очракта... Аның Октябрь, Аксубай, Чирмешән районнарында 7 сәүдә ноктасы бар. Җитәкчелеккә аларның барысында да эшнең оештырылуын, товар ассортиментын контрольдә тоту, шул ук вакытта товар әйләнешенә карап, халыкның ихтыяҗын өйрәнү мөмкинлеге зур. Товар дигәннән, предприятие аны «алыпсатар» арадашчылар аркылы түгел, ә үзәкләштерелгән чыганаклар аркылы килешү нигезендә юнәтә. Татарстан шәһәрләре, Башкортстан, Удмуртия, Самара, Ульяновск өлкәләреннән төзелеш материаллары, хуҗалык товарлары кайтарыла. Төп поставщиклар географиясе киңәя. Шуның нәтиҗәсе буларак, халыкка тәкъдим ителә торган товарлар ассортименты да арта. Товарларны кибеткә әллә ни зур өстәмәләрсез чыгару өчен аларны поставщиклардан үз транспортлары белән кайтартырга тырышалар.

Инде алда телгә алынган фикеребезгә кире әйләнеп кайтып, предприятиенең үз - үзен ашатып яшәүче саннарына да мөрәҗәгать итик. Узган биш айда биредә товар әйләнеше 560 миллион сум тәшкил иткән, 175 миллион сум күләмендә тулай керем алынган. Табыш - 18 миллион сум тәшкил иткән. Рентабльлелек дәрәҗәсе исә 3,2 процент. Соңгысы предприятиегә яннан өстәмә ярдәмсез, чыгымсыз, үз аягында нык итеп басып торырга мөмкинлек бирә.

Предприятиенең үз хезмәткәрләре алдында да йөзе чиста - хезмәт хакын айныкын - айга (ә ул уртача 600 мең сум) алып баралар алар.

Предприятиенең банк картотекалары буенча да бурычы юк. Бу товар, хезмәт күрсәтү өчен үзвакытында исәп - хисап үткәрергә мөмкинлек бирә.

Коллективның авыл халкының ихтыяҗын өйрәнү буенча да бай тәҗрибәсе бар. Авылларга чыгып сату - шуларның берсе. Авыл халкында акча юклыгын белә торып та, кибетчеләр кайчакта авылдан бик аз «выручка» белән кайтсалар да, сәүдә итүнең бу алымыннан ваз кичкәннәре юк. Бүгенге шартларда кайдадыр барып, нидер сатып алып кайту өчен транспорт табыштыру да гади эш түгел бит.

Предприятиенең ике еллап элек ачылган столярлык цехының да ярдәме зур. Биредә халыктан тәрәзә, ишек блоклары ясау буенча индивидуаль заказлар кабул ителә. Ә заказ бирүчеләр аз түгел: биредә эшләнгән столярлык әйберләренең бәясе заводныкыннан күпкә түбән.

Кыскасы, экономик яктан ныгытылып дөрес оештырылган хезмәтколлективның базар шартларына яраклашып зыянсыз эшләвенең нәтиҗәсе шулар. Берничә ел эчендә республикадагы шундый төрдәш предприятиеләрнең 15тән 5кә калуы һәм, шуларның берсе безнең районныкы булуы да шул хакта сөйли.

**Р.ГИНЯЕВА.**




## Сәяхәтче ханым

Дүрт урынлы америка вертолеты «Робинзон Р - 44кә» утырып, Дженифер Мурри дигән 56 яшьлек хатын дөнья тирәли сәяхәткә чыккан. Аңа ире (Гонконгтагы «Дойче банк» хуҗасы) шушы кыйммәтле вертолетны бүләк иткән, әмма үзенең карчыгы белән сәфәргә чыгарга вакыт юк икән.

32 яшьлек очучыны яллап, Д.Мурри сәфәргә чыккан һәм 97 көндә, 26 илдә туктап, дөньяны әйләнеп чыгарга булган. Эше уңса, карчык вертолетта дөнья гизгән беренче хатын - кыз булачак. Вертолетны ул үзе дә йөртә белә һәм, вертолетка утырганда, елмаеп: «Әлбәттә, бу акылсызлыкның чиге инде!» - дигән.

## Сөлек дәвалый да, үтерә дә

Бакуда яшәүче Фаик икенче тапкыр өйләнә. Беренче хатынынннан Фәрид исемле 5 яшьлек улы калган була. Үги ана башта ук Фәридне яратмый, иреннән баласын интернатка яисә туган - тумачасына урнаштыруын таләп итә. Ата кеше бу тәкъдимне катгый төстә кире каккач, үги ана әлеге баладан котылуның явыз, җинаятьчел юлын таба. Бер банкага сөлекләр салып, ире эшкә киткәч көн саен баланың борын тишегенә сөлек җибәрә башлый. Бала чирли. Әтисе табибларга мөрәҗәгать иткәндә инде соң була. Сөлекләр баланың миенә үк үтеп кергәннәр дә, ми күзәнәкләрен суыралар икән. Бу хәлне белгәч, Фаик ачудан хатынын үтерә. Үги ананың коточкыч җинаятен исәпкә алып, ата кешенең үз-үзен белештермәс хәлдә шундый адым ясавын суд аклаган, ягъни аны шартлы рәвештә ике елга хөкем иткән.

## Кабердән ишетелгән аваз

Төнлә бер карак кибеткә керә, касса куелган стойканы эзләп таба. Шырпы сызмакчы була- кабынмый. Дөм караңгы кибеттә кабердән ишетелгәнгә охшаш тоник тавыш яңгырый.

-Әллә кабынмыймы? Башка тартманы кара...

Шуннан соң җенпәриләр көлгәне ишетелә. Коты алынган карак өнсез булып егыла. Шемах шәһәре читендәге кибет хуҗасына полиция урынына «ашыгыч ярдәм» чакырырга туры килә. Аңына килгәч, карак кибет хуҗасыннан кабат мондый нәрсә кулланмавын сорый.

**(«Новая страшная газета»).**



## КАРТЛАРГА ДА САУЛЫК КИРӘК

Картайгач кешегә дөньяның бөтен чирсырхавы ябыша икән. Мине дә әнә шул авырту - сырхаулар Чулпан участок шифаханәсенә китерде. Дөресен әйтим, килгәндә гади бер участок шифаханәсендә үземне терелтеп чыгарсыларына ышанып та җитмәгән идем. Чөнки матбугат-радиодан беләм: зур шәһәр шифаханәләрендә дә хәлләр шәптән түгел. Әмма бирелә дәвалана башлагач ялгышуымны аңладым. Иң әүвәл биредәге чисталыкка, персоналның авыруларга булган мөнәсәбәтенә тан калдым. Сырхаулар процедураларны вакытында алалар, ашату әйбәт, бер ай эчендә мин шифаханәдән терелеп кеше булып чыктым. Үземне аякка бастыруда көчләрен дә, вакытларын да кызганмаган табибларга, шәфкать туташларына, аеруча Дилбәр Фәритовна Шәяхмәтова белән шәфкать туташы Алевтина Владимировна Галимовага рәхмәтем зур минем. Казан ягыннан килеп безнең төбәктә бәхетен тапкан, яшь булуына карамастан халык ихтирамын яуларга өлгергән Дилбәр Фәритовнага карата әйтелгән рәхмәт сүзләренә аның кулларыннан дәва алырга өлгергән башка авырулар да кушыла.

**И. ГЫЙЛӘҖЕВ.**
**Кәкре Атау авылы.**




## Сатабыз

**1992 елгы ВАЗ-21063.** Мир урамы,37-1.

***

**6х4 метрлы чанадагы гараж**. Тел: 5-12-47.

* * *

**Яхшы хәлдәге таккычлы «Днепр-11» мотоциклы кыйммәт түгел**. Школьная урамы, 29-12.

* * *

**1980 елгы ВАЗ-2102, кыйммәт түгел**. Тел: 5-13-8 (18 сәгатьтән соң).

* * *

**12 сутый участогы белән яхшы хәлдәге агач йорт** Тел: 2-27-52.

* * *

**1 бүлмәле хосусыйлаштырылган фатир.** Тел: 5-28-62.

***

**Яңа «Урал» мотоциклы**. Тел: 2-16-06

***

**Торак йорт 1 бүлмәле фатирга алмаштырыла яки сатыла** .Адрес: Полевая урамы , 11, тел: 5-20-74.

***

## Төрлесеннән

**1994 елда шәһәрнең 3 нче мәктәбе тарафыннан Лилия Вазыйх кызы Нуруллина исеменә бирелгән АС 101598 номерлы аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга.**

***

**Шәһәрнең 1 нче мәктәбен тәмамлау турында Губанов Александр Евгеньевич исеменә бирелгән 0030937 номерлы таныклыкны, югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга.**

***

**Ульяновскидагы 2 бүлмәле фатир (яңа шәһәр) Норлатта шундый укка алмаштырыла**. Тел: шикәр заводы коммутаторы аша 4-10.

**Кадерле якташлар! 28 июнь көнне 10 сәгатьтә Үрнәк поселогында мәчет ачыла. Теләүчеләрне әлеге тантанада катнашырга чакырабыз.**

## Очрашабыз



*1992 елда Якушкино урта мәктәбен тәмамлаучыларның очрашуы 21 июньдә 15 сәгатьтә башлана.*



### Хөрмәтле шәһәрлеләр!



*К. Маркс урамының 51 «а» йортында урнашкан шәһәрдәге беренче «Экспресс-фотосалон»ы сезне түбәндәге хезмәтләрдән файдаланырга чакыра:*

*төсле негатив фотопленкаларны ачыкландыру- 6000 сум;*

*10х15 см. лы төсле фоторәсемнәрне ясау-данәсе 1800 сум;*

*«Кодак» фотоаппаратын прокатка алып тору-тәүлегенә 10000 сум; фотограф чакыру - 1 фото 3600 сум, фотосалонда фотога төшү- 1 фото 3000 сум; пленкаларны ачыкландыру һәм фотографияләрне ясау 1-2 сәгать эчендә башкарыла, тарифны күтәрмичә тизрәк тә эшләргә мөмкин. Түмәрләп заказ бирүчеләргә ташламалар каралган. Фотосалонда алдынгы җитештерүче- фирмалар фототасмалары , фотоальбомнар һ.б. әйберләр бар. «ЭКСПРЕСС-ФОТО» дан алынган пленкалар бушлай ачыкландырыла. Лицензия номеры-А-96 118583.* **Эш вакыты -9.00 дан 18.00 гә, төшке ял-13.00 тән-14.00 кә кадәр.**




БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ N 7184